**ГЛАВА БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Березка, ул.Новостройка, 15А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур, 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22 ноябрь, 2021 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Бәерле, Олыяз, Зур Починок, Шуман торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 22 октябрендәге 22 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2021 елның 5 декабрендә 9.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Бәерле торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Бәерле ав., Яшин ур., 34 йорт (ФАП янында);

1.2. 2021 елның 5 декабрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Олыяз торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Олыяз ав., Яңа төзелеш ур., (10 йорт янында).

1.3. 2021 елның 5 декабрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Зур Починок торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Зур Починок ав., Бакча ур., (5 йорт янында).

1.4. 2021 елның 5 декабрендә 12.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Шуман торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Шуман ав., Үзәк ур., 27 йорт(мәдәният йорты).

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Бәерле торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Бәерле торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500

(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Бәерле торак пунктында зиратны коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Олыяз торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Олыяз торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

-Олыяз торак пунктында җиһазларны монтажлау, балалар мәйданчыгының койма һәм җәяүлеләр юлларын урнаштыру;

- Олыяз торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау;

- Олыяз торак пунктында су башнясы коймаларын ремонтлау

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.3. Зур Починок торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Зур Починок торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Зур Починок торак пунктында чишмәгә җәяүлеләр күпере урнаштыру;

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.4. Шуман торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Шуман торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Шуман торак пунктында су башнясын сатып алу һәм урнаштыру

- Шуман торак пунктында су башнясы коймаларын ремонтлау

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенлык авыл җирлегенен
башлык урынбасары В.В.Виногорадов